КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 декабрь г.Казань № 1131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче, 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

икенче абзацта «кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган» сүзләрен «кушымтаның «а» – «г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган» сүзләрен «кушымтаның «а» – «г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

3 бүлектә:

3.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әгәр дә балага айлык пособие билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән ата-ананың балага карата алимент түләү йөкләмәләре барлыкка килсә»;

3.6 нчы пунктта:

икенче абзацка «(банк яки башка кредит оешмасы аша балага айлык пособие алганда)» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 яшьтән зуррак баланың (балаларның) Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан дәүләт яки муниципаль гомуми белем бирү оешмасында йә шәхси гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмә кәгазен;»;

6 бүлектә:

6.5 нче пунктта:

икенче абзацка «банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп (банк яки башка кредит оешмасы аша субсидия, стипендия, пособие алганда), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан, шәхси гомуми белем бирү оешмасыннан, мәгариф оешмасын тәмамлау вакытын күрсәтеп, белем алуны раслый торган белешмә кәгазен; Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасыннан, һөнәри белем бирү оешмасыннан, мәгариф оешмасын тәмамлау вакытын күрсәтеп, белем алуны раслый торган белешмә кәгазен. Белешмә ел саен уку елы башында тапшырыла;»;

6.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Үзәк бүлеге ведомствоара соратып алулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә вәкаләтле оешмалардан түбәндәгеләр турында мәгълүматлар ала:

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекага алынучыны тәрбияләп тору өчен опекунга айлык акчалата түләү бирү вакытлары;

баланың Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында, мәгариф оешмасын тәмамлау вакытын күрсәтеп, белем алуы.»;

6.12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Әгәр дә уку елы чорында опекага алынучыны тәрбияләп тору өчен опекунга айлык акчалата түләү туктатылган очракта яисә Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә көндезге уку формасында белем алучы зат ятим бала, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала, уку чорында ата-анасын икесен дә яки атасын йә анасын югалткан зат статусын алган очракта, өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие күләме уку елы бетәргә калган айлар санына пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарыла һәм югарыда күрсәтеп үтелгән вакыйгаларның берсе башланган айдан соң килә торган айдан башлап түләнелә.»;

9 бүлекнең 9.11 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.11. Пенсионер үз милкендәге торак урынында торак урын милектәшләре булган һәм торак урын милектәшләре булмаган гаилә әгъзалары белән бергә яшәгәндә, аңа транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү пенсионерга караган торак урын мәйданының күләме «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымтаның «а» пунктында яки «б» пунктында гаилә әгъзасы өчен билгеләп күрсәтелгән мәйданның иң чик күләменнән артып китмәү шарты белән билгеләнә.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтага түбәндәге эчтәлекле 4 нче пункт өстәргә:

«4. Милкендә мәйданы (гомуми мәйданы) 20 сутыйдан артып киткән җир кишәрлекләре булган пенсионерларга социаль ярдәм чаралары күрсәтелгәндә, әлеге җир кишәрлекләрен файдаланудан алынган керемнәр исәпкә алына, аларның исәп-хисабы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы нормативын җир мәйданының 20 сутыйдан арткан сутыйлар санына тапкырлау юлы белән хисаплап чыгарыла.

Җир кишәрлекләрен файдаланудан алынган керемнәр турында документлар булганда, пенсионерларга социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә алардагы керемнәр исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин